РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел Олы Кайбыч ав. № 35

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9 статьяның 7 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин